**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ — КАРАР

17.12.2019 г. — № 184

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставының 87, 88, 89 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әтнә район Советының 28.11.2011 ел № 37 карары белән расланган (06.03.2012 ел №68, 26.11.2012 ел №101, 08.10.2013 ел №118, 31.07.2014 ел №156, 01.04.2015 № 178, 31.03.2016 ел № 32, 04.08.2017 ел №76, 16.04.2018 ел №107, 20.05.2019 ел № 156 үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алынганнан соң Әтнә муниципаль районының atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында игълан итәргә.

4. Әлеге карар рәсми халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Әтнә муниципаль районы башлыгы -
Әтнә район Советы рәисе — Г. Г. Хәкимов